РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

15 ноябрь, 2024 ел Кукмара ш. № 273

Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 сентябрендәге 290 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Кукмара муниципаль район Советы **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), 2020 елның 30 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 04 июнендәге 67 номерлы, 2022 елның 18 ноябрендәге 154 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 194 номерлы, 2024 елның 07 маендагы 248 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктында «13323» саннарын «13990» саннарына алмаштырырга;

д) Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫНА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫНА, КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнар белән) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 37 036 |
| Башлык урынбасары | 33 333 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 33 333 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Район башлыгы С.Д. Димитриев